БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» 11 2020 ел № 324

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында финанс – бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 399 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 399 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында финанс – бюджет өлкәсендә контроль буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 11 пунктта вазыйфаи затларның вазыйфалары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка хокукый актлар нигезендә эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча контроль органы вәкаләтләрен үз вакытында һәм тулысынча үтәргә;

б) контроль чаралар үткәрелә торган контроль объектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

в) контроль чараны уздыру турында контроль органы хокукый акты нигезендә контроль чаралар үткәрергә, кирәк булганда контроль чараны уздыру турында контроль органының хокукый акты күчермәсен күрсәтергә;

г) контроль чара уздырганда контроль объекты эшчәнлеген гамәлгә ашыруга комачаулауга юнәлдерелгән гамәлләр кылмаска;

д) контроль объекты җитәкчесен (вәкилен) контроль чараны уздыру турында контроль органының хокукый акты күчермәсе белән, контроль чараны уздыру вакытын туктатып тору, яңадан торгызу һәм озайту турында, тикшерү (ревизия) төркеме составын үзгәртү турында контроль органының хокукый акты белән, шулай ук контроль чаралар нәтиҗәләре белән (актлар, бәяләмәләр) таныштыру;

е) күчмә тикшерү (ревизия, тикшерү) барышында контроль объекты эшчәнлеген фактта өйрәнү (карап чыгу, инвентаризацияләү, күзәтү, кабат исәпләү, экспертиза, тикшеренү, контроль үлчәү (үлчәп чыгу)) буенча контроль гамәлләр үткәргәндә контроль объектының җитәкчесенә, вазыйфаи затына яисә башка хезмәткәренә катнашуга комачауламаска һәм контроль чара предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

ж) Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган очракларда ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр җибәрергә;

з) Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган очракларда мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамәләр җибәрергә;

и) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча эш алып барырга;

к) гавами-хокукый берәмлеккә зыянны каплау, Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда сатып алуларны гамәлгә яраксыз дип тану турында дәгъва гаризасы белән судка мөрәҗәгать итәргә;

л) җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу (гамәл кылмау) фактын ачыклау турында мәгълүматны һәм (яисә) мондый фактны раслый торган документларны һәм башка материалларны хокук саклау органнарына җибәрергә;

м) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль орган (вазыйфаи зат) адресына мондый орган компетенциясенә караган хокук бозу билгеләре турында таныклый торган хәлләрне һәм фактларны ачыклау турында мәгълүматны һәм (яисә) мондый фактларны раслый торган документларны һәм башка материалларны җибәрергә.»;

1.2. 10 пунктта вазыйфаи затларның хокуклары исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) нигезләнгән гарызнамә нигезендә язмача яки телдән тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр (алга таба - контроль чаралар) үткәрү өчен кирәкле булган мәгълүматны, документларны һәм материалларны, шулай ук аларның күчермәләрен соратырга һәм алырга;

б) контроль объектыннан контроль чараларын уздыру өчен кирәкле аңлатмаларны язмача яки телдән алырга;

в) күчмә тикшерүләр (ревизияләр, тикшерүләр) барышында шәхесне таныклаучы документны (хезмәт таныклыгын) һәм контроль чара үткәрү турында контроль органы хокукый актының күчермәләрен күрсәткәндә, контроль чарасы үткәрелә торган контроль объектлары булган биналарга һәм территорияләргә тоткарлыксыз керергә, куелган товарлар, башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр нәтиҗәләрен күрсәтүне таләп итәргә;
г) фото-, видео- һәм аудиотехниканы, шулай ук техниканың һәм приборларның башка төрләрен, шул исәптән үлчәү приборларын кулланып, түбәндәгеләрне җәлеп итеп, тикшерү чараларын үткәрү өчен кирәкле экспертизалар билгеләргә (оештырырга):

бәйсез экспертларны (махсуслаштырылган эксперт оешмаларын);

башка дәүләт органнары белгечләрен;

контроль органнары карамагындагы учреждениеләр белгечләрен.

Бәйсез эксперт (махсуслаштырылган эксперт оешмасы) дигәндә контроль чара нәтиҗәләрендә кызыксынмаган, махсус белемнәре, тәҗрибәсе, квалификациясе булган (хезмәткәрләренең махсус белемнәре, тәҗрибәсе, квалификациясе булган), экспертизаны контроль органы белән шартнамә (контракт) нигезендә уздыручы физик зат (юридик зат) аңлашыла;

контроль органы карамагындагы учреждение белгече дигәндә контроль органы җитәкчесе (җитәкчесе урынбасары) йөкләмәсе нигезендә тикшерү чарасын үткәрүгә җәлеп ителә торган контроль органы оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручысы булып торган казна, бюджет, автоном учреждение хезмәткәре аңлашыла;

д) мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны яклау турында Россия Федерациясе законнарын, дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнарын үтәп, эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру өчен дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларына, хуҗасы яисә операторы контроль объекты булган мәгълүмат системаларына керү мөмкинлеген алырга;

е) контроль объекты эшчәнлеген документаль һәм (яисә) фактта өйрәнү буенча, шул исәптән карап чыгу, инвентаризацияләү, күзәтү, кабат исәпләү, экспертиза, тикшеренү, контроль үлчәү (үлчәп чыгу) юлы белән дә, чаралар үткәрергә (оештырырга).»;

1.3. 6 пунктның 9 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.4. 6 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

әлеге Федераль законда каралган килешүне үтәүгә, үзгәртүгә таләпләрне үтәү, шулай ук контракт шартларын, шул исәптән тапшырылган

товарның, башкарылган эшнең (аның нәтиҗәсенең) яисә күрсәтелгән хезмәтнең контракт шартларына туры килү-килмәве өлешендә дә, үтәү»;

1.5. 6 пунктның 7 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.6. 6 пунктның 5 абзацында «каралган» сүзен «нигезендә билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов